| | |
|---|---|
| МЭР<br>ГОРОДА БАВЛЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2026 Баулы шәһәре №2-м

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар, иҗтимагый чаралар оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 14 августындагы 105 номерлы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең (алга таба - Проект) генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Проект буенча ачык тыңлаулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы шәһәре мэры.

3. Ачык тыңлаулар уздыру срогын 2026 елның 22 июненнән 2026 елның 7 июленә кадәр билгеләргә.

4. Ачык тыңлауларда каралачак Проект экспозициясен 2026 елның 22 июнендә ачарга.

4.1. Экспозицияне ачу урыны:

- Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 й. адресы буенча.

- Баулы муниципаль районы сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: www.bavly.tatarstan.ru.

4.2. Экспозициядә булу режимы:

- Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 й.адресы буенча.

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Ачык тыңлауларда катнашучылар Мәскәү вакыты белән 2026 елның 22 июненнән 2026 елның 7 июленә кадәр эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр ачык тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язма рәвештә түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар оештыручыларга: Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 йорт, 19 каб.

- bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Ачык тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын (алга таба - ачык тыңлауларны оештыручы) билгеләргә.

7. Ачык тыңлауларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча ачык тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында, проект буенча ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында 2026 елның 22 июненнән 2026 елның 7 июленә кадәр эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2026 елның 5 маендагы 1-м номерлы Татарстан Республикасы Баулы шәһәре мэры карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы шәһәре мэры И.И. Гозәеров